СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№ 2-35 24.09.2018 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 24 номерлы карары, Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 6-34 номерлы карары, Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 02 нче апрелендә кабул ителгән 2-30 номерлы (17.09.2018 №5-34 редакцисеяләрендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:**
- Түбән Тәкәнеш торак пунктында Куйбышев урамын төзекләндерү;
- Урта Тәкәнеш торак пунктында Яшләр урамын төзекләндерү;
- Югары Тәкәнеш торак пунктында Үзәк урамын төзекләндерү;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы Р.Җ. Хәмизуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Хәмизуллин Р.Җ.